# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 14.11.2025 г.** **№ 1**

« Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә , « Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 31 октярендәге 2 номерлы карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә 15.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

1) «Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүчеләрдән тыш, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәрбер гражданнардан 1500 сум күләмендә 2026 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)
- чишмә ремонты (төзелеш материаллары сатып алу, махсус техника арендасы, килешү буенча эш һәм күрсәткән хезмәткә түләү)

2) ) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _14__ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - __9__ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен __9__катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен ____0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Яңа Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп :

1) «Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүчеләрдән тыш, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәрбер гражданнардан 1500 сум күләмендә 2025 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм

алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)
- чишмә ремонты (төзелеш материаллары сатып алу, махсус техника арендасы, килешү буенча эш һәм күрсәткән хезмәткә түләү)
2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина